**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«12» октябрь 2022 ел №23/2

**Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнар, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2022 елның 1 июлендәге 02-06-2022/9 номерлы протесты Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Уставы нигезендә Теләнче Тамак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне расларга (бирелә).
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Теләнче Тамак авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Ш. Нәҗметдинов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге Советының 2022 елның «12» октябрендәге 23/2 номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне (алга таба – төзекләндерү өлкәсендә контроль) гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Төзекләндерү өлкәсендә контроль предметы булып юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның (алга таба – контрольдәге затлар) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләрен (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре), инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге таләпләрен (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәве тора.

1.3. Төзекләндерү өлкәсендә контроль Телэнче Тамак авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет, җирлек) тарафыннан башкарыла.

1.4. Башкарма комитетның төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазифаи затлары булып җирлек башлыгы, шулай ук Башкарма комитет секретаре (алга таба – контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар) тора. Күрсәтелгән Башкарма комитет вазыйфаи затларының вазыйфаи бурычларына аларның вазыйфаи инструкциясе нигезендә төзекләндерү өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру керә.

Төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга һәм җаваплылыкка ия.

1.5. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашыру, профилактик чараларны, контроль чараларны оештыру һәм үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.6. Башкарма комитет түбәндәгеләрне үз эченә алган Төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешен контрольдә тота:

1) чиктәш территорияләрне карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

2) төзекләндерү элементларын һәм объектларын карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән таләпләр:

- азмобильле халык төркемнәренең мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик культура һәм спорт, халыкка социаль хезмәт күрсәтү объектларына иркле керә алуына комачауламый торган коймалар урнаштыру буенча;

- торак булмаган биналарның, корылмаларның, башка биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның фасадларын, шулай ук төзекләндерүнең башка элементларын һәм җәмәгать урыннарын карап тоту буенча;

- инженерлык корылмаларын эксплуатацияләү өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә алган махсус билгеләрне, язмаларны карап тоту буенча;

- җир эшләрен башкаруга Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары һәм Төзекләндерү кагыйдәләре, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән җир эшләрен башкару тәртибе нигезендә бирелгән рөхсәт нигезендә җир эшләрен гамәлгә ашыру буенча;

- биналарга һәм аларның керү урыннарына иркле үтеп йөрү юлларын, шулай ук ишегалларына иркле керүне тәэмин итү, җәяүлеләр куркынычсызлыгын һәм, инвалидларны һәм башка азмобильле халык төркемнәрен кертеп, җир эшләрен башкару чорына куркынычсызлыкны тәэмин итү;

- транспорт чараларын урнаштыру Төзекләндерү кагыйдәләре белән чикләнгән газонда яисә башка яшелләндерелгән яисә рекреацион территориядә транспорт чараларын урнаштыруга юл куймау турында, шулай ук транспорт чараларын эксплуатацияләү, хезмәт күрсәтү яки ремонтлау вакытында, йөк ташыганда яисә төзелеш мәйданчыкларыннан чыкканда (тент булмау яки капланмау аркасында) гомуми файдалану территорияләрен транспорт чаралары белән пычратуга юл куймау турында;

3) кышкы чорда җирлек территориясен җыештыру буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән биналарны, корылмаларны кардан, боз катламыннан һәм боз сөңгеләреннән чистарту буенча чаралар үткәрүне контрольдә тотуны кертеп;

4) җәйге чорда җирлек территориясен җыештыру буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән карантиндагы, агулы һәм чүп үләннәрен ачыклау, аларга каршы көрәш, аларның чыганакларын табу, бетерү буенча мәҗбүри таләпләрне кертеп;

5) махсус янгынга каршы режим вакытында өстәмә мәҗбүри янгын куркынычсызлыгы таләпләре;

6) гомуми файдаланудагы территорияләрдә җир асты коммуникацияләрен сузу, үзгәртеп кору, ремонтлау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

7) яшел утыртмаларны утырту, саклау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән кисү билеты һәм (яки) агачларны һәм куакларны күчереп утырту рөхсәте нигезендә агачлар һәм куаклар бетерү (кисеп ату), күчереп утырту буенча мәҗбүри таләпләр, әгәр мондый документлар (кисү билеты, күчереп утырту рөхсәте) Төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракларда бирелергә тиеш булса;

8) каты коммуналь калдыкларны туплау өчен мәҗбүри таләпләр;

9) хайваннары йөртү буенча мәҗбүри таләпләр һәм гомуми файдаланудагы территорияләрдә һәм Төзекләндерү кагыйдәләрендә каралган башка территорияләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын көтү рөхсәт ителмәү турында таләпләр.

Башкарма комитет контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан аларның компетенциясе чикләрендә бирелгән таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмәләрнең үтәлешен контрольдә тота.

1.7. Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү элементлары дигәндә декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлау һәм бизәү төрләре, шул исәптән биналар, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, капитал булмаган стационар булмаган төзелмәләр һәм корылмалар, мәгълүмати щитлар һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган күрсәткечләр аңлашыла.

Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү объектлары дигәндә төзекләндерү буенча эшчәнлек алып барыла торган төрле функциональ юнәлештәге территорияләр аңлашыла, шул исәптән:

1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары), гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләрен урнаштыру территорияләре);

2) урам-юл челтәре элементлары (аллеялар, бульварлар, магистральләр, тыкрыклар, мәйданнар, юллар, проспектлар, разъездлар, төшү юллары, трактлар, тупиклар, урамнар, шоссе);

3) ишегалды территорияләре;

4) балалар һәм спорт мәйданчыклары;

5) хайваннарны йөртү өчен мәйданчыклар;

6) парковкалар (парковка урыннары);

7) парклар, скверлар, башка яшел зоналар;

8) техник һәм санитар саклау зоналары;

Әлеге Нигезләмәдә койма җайланмалары дигәндә капкалар, ян капкалар, шлагбаумнар, шул исәптән автоматик һәм декоратив коймалар аңлашыла.

1.8. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырганда бәяләү һәм хавеф белән идарә итү системасы кулланылмый.

## 2. Закон белән сакланган кыйммәтләргә зарар (зыян) куркынычын профилактикалау

2.1. Башкарма комитет төзекләндерү өлкәсендә, шул исәптән профилактик чаралар үткәрү юлы белән, контрольне гамәлгә ашыра.

2.2. Башкарма комитет тарафыннан профилактик чаралар контрольдәге затларның мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәвен стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар китерүгә китерүче шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү, контрольдәге затларга мәҗбүри таләпләрне, аларны үтәү ысулларын җиткерү максатында башкарыла.

2.3. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырганда, зарар (зыян) китерү куркынычын киметүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү контроль чаралар үткәрүгә карата өстенлекле булып тора.

2.4. Профилактик чаралар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган закон белән сакланган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалау программасы нигезендә гамәлгә ашырыла, шулай ук зарар китерү куркынычларын профилактикалау программасында каралмаган профилактик чаралар да үткәрелергә мөмкин.

Профилактик чаралар үткәргәндә контрольдәге объектларның закон белән сакланган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүгә ачыктан-ачык куркыныч тудыруы яки шундый зарар (зыян) китерелгәне билгеләнсә, төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат, контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен, бу хактагы мәгълүматны кичекмәстән җирлек башлыгына җибәрә.

2.5. Башкарма комитет төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырганда, профилактик чараларның түбәндәге төрләре үткәрелергә мөмкин:

1) мәгълүмат бирү;

2) консультация бирү;

2.6. Мәгълүмат бирү Башкарма комитет тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (җирлек бүлеге) (алга таба – районның рәсми сайты) контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә (махсус бүлеккә керү район рәсм сайтының махсус баш (төп) битеннән башкарылырга тиеш), массакүләм мәгълүмат чараларында, контрольдәге затларның шәхси кабинетлары аша дәүләт мәгълүмат системаларында (алар булганда) мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча тиешле белешмәләрне урнаштыру юлы белән һәм башка формаларда гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет районның рәсми сайтындагы контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 3 өлешендә каралган белешмәләрне урнаштырырга һәм актуаль хәлдә тотарга тиеш.

Башкарма комитет шулай ук гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә контроль объектларына куела торган мәҗбүри таләпләр турында халыкка хәбәр итәргә хокуклы.

2.6. Контрольдәге затларга консультация бирү контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итүдә яки профилактик чаралар, контроль чаралар үткәргәндә башкарыла һәм 15 минуттан артмаска тиеш.

Гражданнарны шәхси кабул итү җирлек башлыгы һәм (яки) контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелә. Кабул итү урыны, кабул итү өчен

билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат районның рәсми сайтында контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә урнаштырыла.

Консультация бирү түбәндәге сораулар буенча телдән яки язма формада башкарыла:

1) төзекләндерү өлкәсендә контрольне оештыру һәм тормышка ашыру;

2) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

3) контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе;

4) мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат алу, аларның үтәлешен бәяләү контроль чаралар кысаларында Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

Контрольдәге затларга телдән консультация бирү шулай ук гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә башкарылырга мөмкин.

2.7. Язма формада консультация бирү контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан түбәндәге очракларда башкарыла:

1) контрольдәге зат консультация сораулары буенча язма җавап бирү турында язма запрос биргән;

2) консультация вакытында куелган сорауларга телдән җавап биреп булмый;

3) бирелгән сорауларга җавап өстәмә мәгълүмат сорауны таләп итә.

Консультация биргәндә, контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш.

Консультация барышында конкрет контроль чарасын, контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның, башка контроль чарада катнашучыларның карарларын һәм (яки) гамәлләрен бәяләүне, шулай ук тикшерү чарасы кысаларында үткәрелгән экспертиза, сынаулар нәтиҗәләрен үз эченә алган мәгълүмат бирелә алмый.

Контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затка консультация барышында билгеле булган мәгълүмат Башкарма комитет тарафыннан контрольдәге затны мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча бәяләү максатларында куллана алмый.

Контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан консультацияләрне исәпкә алу журналы алып барыла.

Башкарма комитетка контрольдәге затлардан һәм аларның вәкилләреннән бертөрле биш һәм аннан күбрәк мөрәҗәгать килгән очракта, консультация бирү Башкарма комитетның рәсми сайтындагы контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә җирлек башлыгы яки контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле зат имзалаган язма аңлатманы урнаштыру юлы белән башкарыла.

**3. Контроль чараларны һәм контроль гамәлләрне тормышка ашыру**

3.1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырганда Башкарма комитет тарафыннан әлеге чаралар кысаларында контроль чараларның һәм контроль гамәлләрнең түбәндәге төрләре үткәрелергә мөмкин:

1) инспекция визиты (мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдәге затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур бүлекчәләре) урнашу (эшчәнлеген башкару) урынында булырга тиешле документларны карау, сораштыру, таләп итү аша), язма аңлатмалар, инструменталь тикшерү алу;

2) рейд каравы (карау, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза аша);

3) документар тикшерү (язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, экспертиза аша);

4) күчмә тикшерү (карау, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза аша);

5) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (төзекләндерү өлкәсендә контроль объектлары турында белешмәләр җыю һәм анализлау, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати элемтә барышында керә торган мәгълүматлар аша, мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контрольдәге затлар тарафыннан тапшырыла, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматлар, «Интернет» челтәреннән мәгълүматлар, шулай ук автомат

режимда эшләүче, фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең техник чараларын файдаланып алынган белешмәләр);

6) күчмә тикшерү (карау, инструменталь тикшерү (видеоязма куллану белән), сынау, экспертиза).

3.2. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү һәм күчмә тикшерү Башкарма комитет тарафыннан контрольдәге затлар белән үзара бәйләнешсез үткәрелә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән контроль чаралар планнан тыш чаралар рәвешендә үткәрелә.

Планнан тыш контроль чаралар прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына үткәрелергә мөмкин.

3.4. Контрольдәге затлар белән үзара бәйләнештә үткәрелә торган контроль чараларны үткәрү өчен нигез булып тора:

1) Башкарма комитетта гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре (гаризалары), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат кергәндә, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү хакында яки зарар (зыян) китерү куркынычы турында мәгълүматлар булу, шулай ук контроль чараларны, шул исәптән башка контрольдәге затларга карата уздырылучы контроль чараларны да кертеп, мондый мәгълүматлар алу;

2) конкрет контрольдәге затларга карата тикшерү чаралары үткәрү турында Россия Федерациясе Президентының йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең йөкләмәсе;

3) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

4) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмәне үтәү срогы чыкса - контрольдәге зат тарафыннан үзенә тапшырылган күрсәтмәдә каралган документлар һәм белешмәләр тапшырылмаган яисә тапшырылган документлар һәм белешмәләр нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмәнең үтәлеше турында нәтиҗә ясап булмый торган очракларда.

3.5. Контрольдәге зат белән үзара бәйләнештә үткәрелә торган контроль чаралар Башкарма комитетның контроль чарасын үткәрү турында күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә.

3.6. Закон белән сакланган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү турында яки зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләр нигезендә тикшерү чарасы үткәрү хакында Башкарма комитет карары кабул ителгән очракта, мондый күрсәтмә төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затның контроль чара үткәрү турында нигезләнгән күрсәтмәсе нигезендә кабул ителә.

3.7. Контрольдәге затлар белән үзара бәйләнештән башка уздырыла торган контроль чаралар, җирлек башлыгы йөкләмәсе нигезендә, Башкарма комитетның эш планнарындагы йөкләмә, шул исәптән «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә.

3.8. Гражданнарга, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата контроль чаралары «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законт нигезендә контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә.

3.9. Башкарма комитет төзекләндерү өлкәсендә контрольне оештырганда башка органнардан яисә әлеге органнарның ведомство буйсынуындагы, бу документлар һәм белешмәләр булган оешмалардан документларны һәм (яки) белешмәләрне ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, шул исәптән электрон формада ала. Күрсәтелгән документларның һәм (яки) белешмәләрнең исемлеге, аларны тапшыру тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р күрсәтмәсе белән расланган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә әлеге органнарның ведомство буйсынуындагы, бу документлар һәм белешмәләр булган оешмалардан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә сорала торган һәм алына торган документлар һәм

(яки) мәгълүматлар исемлеге, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2021 елның 6 мартындагы 338 номерлы карары белән расланган Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан башка органнардан яисә әлеге органнарның ведомство буйсынуындагы, бу документлар һәм белешмәләр булган оешмалардан дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен, муниципаль контроль төрләрен оештырганда һәм тормышка ашырганда алына торган документлар һәм (яки) белешмәләр бирү кагыйдәләре белән билгеләнгән.

3.10. Контрольдәге затлар булган шәхси эшмәкәр, граждан Башкарма комитетка контроль чара үткәргәндә катнаша алмау турында мәгълүмат бирергә хокуклы очракка (шуңа бәйле рәвештә контроль чараны уздыру Башкарма комитет тарафыннан шәхси эшмәкәрнең, гражданның Башкарма комитетка әлеге мөрәҗәгате өчен сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле срокка күчерелә (ләкин 20 көннән дә артыкка түгел) бер үк вакытта түбәндәге шартларны үтәү кирә:

1) контрольдәге затның яисә аның вәкиленең булмавы төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затның контроль чара үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләүгә комачауламый, контрольдәге затка контроль чарасын үткәрү турында тиешенчә хәбәр ителгән очракта;

2) закон белән сакланган кыйммәтләргә турыдан-туры яки фактик зарар (зыян) китерү куркынычы билгеләренең булмавы;

3) контроль чара үткәргәндә контрольдәге зат булмавының нигезле сәбәпләре (контрольдәге затның авыруы, аның командировкасы һ.б.) бар.

3.11. Күчмә тикшерүне үткәрү вакыты 10 эш көненнән артып китә алмый.

Кече эшмәкәрлекнең бер субъектына карата күчмә тикшерүне уздыру барышында үзара бәйләнешнең гомуми срогы кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артмаска тиеш.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген башкаручы оешмага карата күчмә тикшерүне үткәрү срогы оешманың һәр филиалы, вәкиллеге, аерым структур бүлекчәсе яки җитештерү объекты буенча аерым билгеләнә.

3.12. Контроль чараларны тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар һәм контроль гамәлләр кылуга җәлеп ителгән затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне (бозуны) исбатлау өчен тикшерү чараларын үткәрүнең барлык очракларында контроль чараларын үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә торган фотографияләр, аудио - һәм видеоязмалар, геодезик һәм картометрик үлчәүләр кулланылырга мөмкин. Фотога төшерү, аудио һәм видеоязма үткәрү, геодезик һәм картометрик үлчәүләр һәм әлеге максатларда файдаланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль чарасы нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта һәм контроль чара кысаларында үткәрелә торган тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмәдә чагылдырыла.

3.13. Контроль чараның нәтиҗәләренә контрольдәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү, мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү һәм (яки) туктату өчен шартлар тудыру, бозылган хәлне торгызу, вәкаләтле органнарга яки вазыйфаи затларга җаваплылыкка тарту турында мәсьәләне карау өчен мәгълүмат җибәрү һәм (яки) Башкарма комитет тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның каралган 90 статьясы 2 өлешендә каралган чараларны куллану керә.

3.14. Контрольдәге зат белән үзара бәйләнешне күздә тотучы контроль чараны үткәргәннән соң, контроль чара акты төзелә. Мондый чараны үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, актта нинди мәҗбүри таләпнең бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә. Контроль чара тәмамланганчы ачыкланган бозу очраклары бетерелсә, актта аны бетерү факты күрсәтелә. Мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлиле булган документлар, башка материаллар актка теркәлергә тиеш. Котроль чаралар үткәргәндә тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлә.

Актны рәсмиләштерү контроль чараны уздыру урынында мондый чара тәмамланган көнне башкарыла, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса.

Үткәрүе прокуратура органнары тарафыннан килештерелгән контроль чара акты, аны рәсмиләштергәннән соң, Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестры аша прокуратура органнарына җибәрелә.

3.15. Контроль чаралар турында мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында урнаштырыла.

3.16. Контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан башкарыла торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында хәбәр итү Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында әлеге гамәлләр һәм карарлар турында белешмәләр урнаштыру, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт һәм муниципаль функцияләрне электрон формада башкару өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктура ярдәмендә, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы) һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы) аша аларны контрольдәге затларга җиткерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырмый торган контрольдәге зат булып торучы гражданга контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан башкарыла торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында документларны кәгазьдә җибәрү юлы белән, аның Башкарма комитет адресына кәгазьдә документлар алу зарурлыгы турында хәбәрнамәне җибәрү яисә Башкарма комитетның контрольдәге затның электрон почта адресы турында белешмәләре булмау һәм документларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша электрон рәвештә җибәрә алмау очрагында (әгәр шәхеснең Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында хисап язмасы булмаса яки ул Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү процедурасын тәмамламаса) хәбәр ителә. Күрсәтелгән граждан Башкарма комитетка документларны кәгазьдә җибәрергә хокуклы.

2023 елның 31 декабренә кадәр контрольдәге затларга контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан башкарыла торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында хәбәр итү, контрольдәге затка документлар һәм белешмәләр җибәрү, контрольдәге затка электрон формада хәбәр итә алмаган очракта яки контрольдәге зат соравы буенча, почта элемтәсеннән файдаланып, шул исәптән кәгазьдә дә гамәлгә ашырыла ала.

3.17. Контроль чараны үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозулар булмаган очракта, бу турыда белешмәләр Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына кертелә. Контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирергә, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын кисәтүгә юнәлдерелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

3.18. Контроль чара үткәргәндә контрольдәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, Башкарма комитет (контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат) Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә тиеш:

1) контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң контрольдәге затка, бетерү срокларын күрсәтеп, ачыкланган бозуларны бетерү турында һәм (яки) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмә бирергә;

2) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне булдырмау яки аның китерелүен туктату һәм гражданнарга, оешмаларга закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы булу турында һәм контроль чараны үткәргәндә төзекләндерү өлкәсендә контроль объектына ия булган һәм (яки) аннан файдаланучы гражданның, оешманың эшчәнлеге турыдан-туры закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы яисә мондый зыян китерү (зыян) китерүе ачыкланган очракта, аны булдырмау ысуллары турында теләсә нинди мәгълүмат алу ысулы белән хәбәр итү буенча кичекмәстән Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрергә;

3) контроль чара барышында җинаять яки административ хокук бозу билгеләрен ачыклаганда, тиешле мәгълүматны үз компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрергә

яисә, тиешле вәкаләтләр булганда, гаепле затларны законда билгеләнгән җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә;

4) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерүне контрольдә тоту, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, закон белән саклана торган кыйммәтләргә мөмкин булган зарар (зыян) китерүне булдырмау, күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгәндә, аның үтәлешен тәэмин итү буенча, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турында таләп белән судка мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр, чаралар күрергә, әгәр мондый чара законнарда каралган булса;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирү, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын кисәтүгә юнәлдерелгән башка чаралар уздыру турында мәсьәләне карарга.

3.19. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимиятнең федераль органнары һәм аларның территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, оешмалар һәм гражданнар белән үзара бәйләнештә тора.

Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль чара үткәрү барышында Россия Федерациясе законнарында административ һәм башка җаваплылык каралган закон таләпләрен бозулар ачыкланган очракта, контроль чара актында ачыкланган бозу билгеләренең булуы турында мәгълүмат күрсәтелә. Контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар әлеге актның күчермәсен, тиешле җаваплылыкка тарту өчен, вәкаләтле хакимият органына җибәрәләр.

3.20. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда шикаятьләр бирүнең судка кадәр тәртибе кулланылмый.

**4. Төзекләндерү өлкәсендә контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан зурлыклары**

4.1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020елның 31 июлендәге 248-ФЗ Федераль законның 30 статьясы нигезендә башкарыла.

4.2. Контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан зурлыклары, төзекләндерү өлкәсендә контроль өчен индикатив күрсәткечләр җирлек Советы тарафыннан раслана.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары булып торалар:

1. Җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләрен бозу билгеләрен ачыклау.

2. Инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең мөмкинлеген тәэмин итүгә федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен ачыклау.

3. Дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, иҗтимагый берләшмәләрдән, шәхси эшмәкәрләрдән, гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан закон белән саклана торган кыйммәтләргә мәҗбүри таләпләрне бозу һәм (яки) зарар (зыян) китерү куркынычын турында таныкларга мөмкин булган гамәлләр (гамәл кылмау) хакында белешмәләр керү.

4. Мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын бетерү турында контроль чара нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлеше турында мәгълүматның булмавы.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өлкәсендәге төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан зурлыклары, индикатив күрсәткечләр**

1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан зурлыклары:

| Төп күрсәткечләр | Максатчан зурлыклар (%) |
|---|---|
| Мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары саныннан бетерелгән мәҗбүри таләпләрне бозулар өлеше | 70 - 80 |
| Контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) контроль чаралар үткәргәндә кергән шикаятьләрнең гомуми саныннан нигезле шикаятьләр өлеше | 0 |
| Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарларның суд тарафыннан юкка чыгарылган өлеше, карарларны гомуми саныннан | 0 |

2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өлкәсендәге индикатив күрсәткечләр:

1) муниципаль контроль органнарына мәҗбүри таләпләрне бозу турында гражданнар һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләр саны (3);

2) муниципаль контроль органы тарафыннан үткәрелгән планнан тыш контроль чаралар саны (3);

3) муниципаль контроль органы тарафыннан планнан тыш контроль чараны уздыруны килештерү турында прокуратура органнары кабул иткән карарлар саны (3);

4) муниципаль контроль органы тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары (3);

5) мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары бетерелү саны (3);

6) контроль чарага карата кабул ителгән каршылыклар саны (0);

7) мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында муниципаль контроль органы биргән күрсәтмәләр саны (3).